СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫН ИЖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 6 нюленнән бирле чыга | №91 (7264) | 30 июль, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91“ пресс-группасы хәбәр итә

Көннәрнең әйбәт торуы урып-җыюны оешкан төстә алып бару өчен җирлек тудыра. 29 июльгә 25 хуҗалык уҗым культураларын җыюны тәгәлләде. Әлегә уҗым культуралары уңышы гектардан 17,1 центнер, борчак 7,7 центнер тәшкил итә.

Хәзер барлык көч сабан культураларын җыюга юнәлдерелгән. Районда 471 гектарда солы җыелды. Нигездә бу эш белән Синдряков исемендәге, «Россия», Кузнецов исемендәге, «Заря» колхозлары әйбәт шөгыльләнәләр. Арпа уңышын җыюда «Большевик», «Чишмә», «Яшь көч» колхозлары бердәм эшлиләр.

# *Кыр батырларына тигезләнегез!*

## Районның ашлык суктыруда иң әйбәт күрсәткечләргә ирешкән алдынгы комбайнчылары

Беренче багана—тоткан урыны, икенче механизаторның исем-фамилиясе, өченче—хуҗалык исеме, дүртенче—комбайн маркасы, бишенче урак башыннан 29 июльгә кадәр суктырылган бөртек (центнерларда).

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Абрамов В. Д. | «Восход» | ДОН-1500 | 5356 |
| 2. | Донсков А. Е. | «Большевик» | ДОН-1500 | 4737 |
| 3. | Кыямов Х. К. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 4365 |
| 4. | Сафин Ә. Ә. | Ульянов исем. | ДОН-1500 | 4013 |
| 5. | Гордюнин Ю. А. | «Заветы Ильича» | ДОН-1500 | 3660 |
| 6. | Хәлимов Т. Х. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 3436 |
| 7. | Ибраһимов Ә. И. | «Игенче» | ДОН-1500 | 3400 |
| 8. | Вафин Р. Р. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 3351 |
| 9. | Хәсәнҗанов Н. Г. | «Чишмә» | ДОН-1500 | 3274 |
| 10. | Шәрәков Ф. Г. | «Алга» | СК-5 | 3250 |
| 11. | Габдрахманов Р. А. | «Игенче» | ДОН-1500 | 3200 |
| 12. | Нуруллин Р. Ә. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 3162 |
| 13. | Матвеев В. А. | «Алга» | СК-5 | 3155 |
| 14. | Гобәйдуллин Ә. Г. | Муса Җәлил исем. | ДОН-1500 | 3033 |
| 15. | Казаков Ю. А. | «Заря» | ДОН-1500 | 3030 |

## 1991 нче ел уңышын уру алдынгылары

Беренче багана—тоткан урыны, икенче—исем-фамилиясе, өченче—хуҗалыклар исеме, дүртенче—машина маркасы, бишенче—урып-җыю башыннан күпме урдырылган (гектарларда). Мәгълүматлар 29 июльгә.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Демьянов Е. М. | «Восход» | СК-5, ЖРБ-4/2 | 313 |
| 2. | Алексеев А. В. | «Сөлчә» совхозы | «——» | 293 |
| 3. | Кыямов Х. К. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 285 |
| 4. | Захаров Л. С. | «Мамык» совхозы | СК-5 | 239 |
| 5. | Миннеголов С. Х. | Муса Җәлил исем. | СК-5, ЖВН-6 | 231 |
| 6. | Хәлимов Т. Х. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 222 |
| 7 | Волков В. Я. | «Заря» | СК-5, ЖВН-6 | 217 |
| 8. | Ахсанов С. Ш. | «Игенче» | СК-5 | 210 |
| 9. | Гордюнин Ю. А. | «Заветы Ильича» | ДОН-1500 | 209 |
| 10. | Зиннуров Ш. Р. | «Игенче» | СК-5 | 205 |
| 11. | Антипов А. Н. | «Россия» | СК-5, ЖВН-6 | 183,7 |
| 12. | Бочкарев А. И. | Мичурин исем. | КПС-5Г | 180 |
| 13. | Сиплатов Ю. В. | «Путь к коммунизму» | КПС-5Г | 175 |
| 14. | Бильданов Н. М. | «Чишмә» | СК-5, ЖРБ-4/2 | 174,72 |
| 15. | Галиуллин Р. Г. | «Алга» | СК-5 | 169 |
| 16. | Яргунов В. Д. | Мичурин исем. | СК-5 | 167 |
| 17. | Саврандейкин В. Н. | «Россия» | СК-5, ЖВН-6 | 164 |
| 18. | Осипов В. В. | «Россия» | СК-5, ЖВН-6 | 158,7 |
| 19. | Васильев Н. Н. | Мичурин исем. | СК-5 | 148 |
| 20. | Ворков А. Х. | «Заветы Ильича» | СК-5 | 147 |



Колхоз чәчүне дә, урып-җыюны да үз көче белән генә башкарып чыга алмый башлады. Бу бигрәк тә транспорт мәсьәләсенә кагылганда аермачык күренә. Нәкъ шул чакта аңа зур ярдәм, һәр минутына игътибар таләп итела дә. Шәһәр транспорт оешмалары хәлне аңлап машиналарын төрле хуҗалыкларга озаттылар. Хәмматкәрим Исламович шул ярдәмчеләрнең берсе. Ул «Үрнәк» колхозына автотранспорт предприятиесеннән килде. Төп эшендә үзенә бирелгән йөкләмәне 104 әр процентка үтәп баручы шофер, билгеле инде, колхозда да сынатмый. Хәмматкәрим көр күңелле, аралашучанлыгы белән дә коллективта абруй казанды. Колхозда аның кебек кешеләр булганда урып-җыюдагы кыенлыклар, күпкә кими, әлбәттә.

Рәсемдә: АТП шоферы Х. И. Алиев.

## Район Советы президиумында

29 июль көнне Х. Х. Морадыймов җитәкчелегендә район Советы президиумының чираттагы утырышы булып үтте. Утырышта соңгы вакытта шәһәр халкын сөт белән тәэмин итүдәге кыенлыкларны бетерү чаралары турындагы мәсьәлә каралды.

Бу мәсьәлә турында район Советы башкарма комитеты рәисе, штаб начальнигы В. В. Богатиков информация ясады. Хәзерге вакытта сөт-май комбинатының сөтне шешәләргә тутыру цехына реконструкция үткәрелә, сөт тутыру линиясе һәм юу автоматы яңалары белән алыштырыла. Реконструкция һәм ремонт эшләрен комбинат эшчеләре, район предприятиеләре, оешмаларыннан килгән белгечләр группасы башкара. Шәһәрдә сөт сатуны өзлексез оештыру өчен өстәмә сыешлыклар, флягалар бирелде, комбинат җитәкчеләренә сөтне сатуга җитәрлек кадәр җибәрергә кушылды. Район Советы президиумында җаваплы хезмәткәрләргә атна ахырына кадәр сөт-май комбинатында ремонт һәм реконструкция эшләрен тәгәлләргә күрсәтмә бирелде.

Утырышта районда урып-җыю эшләренең барышы һәм башка мәсьәләләр дә каралды.

## ● Бер колхоздан язалар

### Урып-җыелды

«Үрнәк» колхозында кырларда үстерелгән икмәкне урып-җыю эше оешкан төстә бара. 408 гектар мәйданда уҗым культуралары урып суктырылып бетте. 60 гектарда борчак та тиз көннәрдә җыеп алынды.

Игеннәрне теземнәргә салуда Фәнил Кәлимуллин аеруча тырышлык күеп эшләде. Теземнәрне җыеп суктыруда СК-5 комбайнында Хәмит Хуҗиәхмәтов ярдәмчесе улы Зөлфәт белән 2500 центнер ашлык суктырдылар.

Миннебай Идиятуллин, Тәлгать Галимов, Касыйм Мөстәкыймов экипажлары да үзара ярышып, нәтиҗәле эшлиләр.

Бүгенге көндә арпаны теземнәргә салу эшләре бара.

### Салам эскертләнә

Берр әттән комбайннар артыннан ук салам басу кырыйларына тарттырыла. 468 гектар мәйдан җир саламнан чистартылды. Салам эскертләүдә тракторчы Фәнис Фәссахов җитәкчелегендә махсус звено төзелде. Әнвәр Гыйләҗев, Габдулла Шәйхиев, Әмир Шәйдуллин, Рафик Хәмзин эшләрен җиң сызганып бик өлгер башкаралар. Алар 100 тонна салам эскертләделәр инде.

### Сөрү бара

Саламы җыелган җирләр чистартылып, аңда сөрү башланды. Ильяс Фәссахов К-700 тракторында 50 гектар мәйданда җир сөрде инде.

240 гектар мәйданда җирләр сөрелеп, тырмаланып, известьләнеп көзге чәчүгә хәзерләнде инде.

Орлык хәзерләүгә дә җитди игътибар бирелә. Ислам Мәсгутов, Нәбиулла Шәйхетдинов орлыкны сортларга аералар.

**И. ШӘЙХИЕВ,**
колхоз экономисты.

● Кискен сигнал

## Әзергә дә хуҗа юк

Бассейнда тиешле чисталык булмау, җыелган суның авыру тудыручы микроорганизмнар өчен уңай җирлек икәнен күздә тотып, шәһәр санэпидстанциясе анда коенуны тыйган иде. Бассейнны чистартып, аңа чиста су тутыру хакында күрсәтмә дә бирелде. Әмма җаваплы оешма (НУРБ) эшне җиңеләйтү максатында булса кирәк, бассейнның төбен чистартмыйгына аңа чиста су агыза башлады. Янәсе, әлеге су белән бассейн үзлегеннән юыла һәм бөтен чүп-чар, җыелган пычрак канализациягә агып китә.

Чынлыкта исә бассейнга китерелгән торбадан әчә торган чиста су берөзлексез һәм һич файдасызга канализациягә агып ята. Шәһәрдә су мәсьәләсе болай да кыен бер вакытта чиста суны шулай әрәм-шәрәм итү үзе бер гаеп икәнен аңларга теләмәүме бу? Бассейн үзе бака күленә әверелгән, сусыз җирләрдә яшел мүк калыккан.

Без шундый битарафкка әйләндек: төзисе юк, зур чыгымнар тотасы түгел, югыйсә. Бары әзер бассейнга хуҗа юк!

**И. АНДАРОВ,**
шәһәр санэпидстанциясе баш врачы.

## Ындыр табагында

Яңа икмәкне кабул итү өчен ындыр табагын бик җентекләп әзерлиләр. Бригадирлар ындыр табагында эшләүче булмас инде дип кайгырып торган булсалар да, беренче икмәк кайткан көнне үк шикләре таралды. Мәктәп укучылары, укытучылар, пенсионер апа-абыйлар—Якуб Ганиев, Нәфисә Сафина, Нурдидә Даутова, Сания Әбделвәлиева, Саимә Галимова кайткан ашлыкны саклау бурычын тиз генә үз кулларына алдылар. Нәтиҗәдә хуҗалык үз көчләре белән, читтән ярдәмгә чакырмыйча өлгереп тора. Хәер, пенсионерлар ындыр табагына гына түгел, кырга да чыгалар.

—Радиодан бер тапкыр мөрәҗәгать иткән идек, борчак тезем нәрен берләштерергә 40 лап хатын-кыз чыккан. Халык вакытның киеренкелеген аңлый, күрәсең, —ди баш агроном Алмаз Гайнетдинов. Әйе, бу көннәрдә колхозчылар тарафыннан аңлау һәм бердәмлек кирәк.

**Ф. ГАЛИМОВА.**
Ульянов исемендәге колхоз.





Мингаяз Вазыйхович Җәләлетдинов гомер итәргә авылны сайлады. Яшьтән техникага гашыйк иде, армиягә киткәнче үк тракторда эшләде. Һәм менә армиядән кайтканнан бирле шул ук тракторда ул. Теләсә нинди нарядны җиренә җиткереп башкара торган сабыр холыклы егет бер үк вакытта Чурабатыр бригадасында бригадирның техника буенча ярдәмчесе дә. Мингаяз Вазыйхович бу эшен дә җиренә җиткереп башкара. Хәер, башкача мөмкин дә түгел, чөнки ул бит шушы җирдә, туган төбәгендә яши.

Рәсемдә: «Комбайн» колхозы механизаторы М. В. Җәләлетдинов.

## *Кыр эшләре ничек бара?*

**Беренче багана—хуҗалыклар исемнәре, икенче—ужым культуралары чәчү өчен җир әзерләү, өченче—тунга сөрүнең барышы (процентларда). Мәгълүматлар 1991 елның 29 июленә.**

| | | |
|---|---|---|
| Синдряков исем. | 44 | — |
| Ульянов исем. | 54 | — |
| «Правда» | 76 | 7 |
| «Восход» | 67 | 6 |
| Мичурин исем. | 65 | 6 |
| «Россия» | 46 | 6 |
| Хафизов исем. | 64 | 22 |
| «Путь к коммунизму» | 45 | 5 |
| Муса Җәлил исем. | 27 | 4 |
| «Родина» | 30 | 7 |
| «Игенче» | 70 | — |
| «Большевик» | 30 | 1 |
| «Заветы Ильича» | 61 | 18 |
| «Знамя Октября» | 54 | 6 |
| «Алга» | 54 | — |
| «Комбайн» | 55 | — |
| XXI партсъезд исем. | 70 | 4 |
| «Татарстан» | 78 | 1 |
| «40 лет Победы» | 54 | 4 |
| «Чишмә» | 24 | 2 |
| «Таң» | 65 | — |
| «Москва» | 25 | — |
| «Үрнәк» | 73 | 4 |
| «Лесная Поляна» | 9 | — |
| «Кондырча» | 28 | 14 |
| Кузнецов исем. | 37 | 6 |
| «Заря» | 27 | 22 |
| «Чирмешән» | 21 | 2 |
| «Ленинский путь» | 52 | 11 |
| «1 нче Май» | 100 | 9 |
| «Төрнәс» совхозы | 34 | 5 |
| «Мамык» совхозы | 34 | — |
| «Рассвет» совхозы | 49 | 11 |
| «Сөлчә» совхозы | 37 | — |
| Хуҗалыкара берләшмә | 68 | 9 |
| «Яшь көч» | 50 | — |
| Район буенча | 49 | 5 |

x x x

Быел район буенча 28147 гектарда ужым культуралары чәчү планлаштырыла. Бу—чәчү планының 52 процентын тәшкил итә. Хафизов исемендәге, «Комбайн», «Татарстан», «Таң», «Кондырча», «Чирмешән» колхозларында, хуҗалыкара берләшмәләрдә ужым культуралары чәчү планының 60 проценттан артыгы күләмендә чәчеләләр. Бу хуҗалыклардан аермалы буларак, Ульянов исемендәге, «Восход», «Беренче Май», «Яшь көч», «Чишмә», «40 лет Победы», Синдряков исемендәге колхозлар әлеге эшнең файдасын аңлап җиткермиләр булса кирәк, ужым культураларына 39—43 процент кына урын бирәләр.

Районда 6173 гектарда ужым бодае чәчеләчәк. «Алга», «Комбайн», XXI партсъезд исемендәге, Кузнецов исемендәге колхозларда, «Төрнәс» совхозында аларны зур мәйданнарда чәчү планлаштырыла. Болар һәммәсе туфрак әзерләүгә җитди карауны сорый. Хәзер ужым арышы чәчә башлауга 1 атна вакыт калуга карамастан, Муса Җәлил исемендәге, «Чишмә», «Москва», «Лесная Поляна, «Чирмешән» колхозларында җир әзерләү 21—27 процент күләмендә генә башкарылды. Аерым хуҗалыкларда азык катнашмалары, берьеллык үләннәрне җыю эшенең әлегәчә тәмамланмавы да бу эшне суза. Игенчеләр алдында бу атнада җир әзерләүне тәмамлау беренчел бурыч булып тора. Хәзер җирне сөрергә түгел, ә аның өске катламын эшкәртүгә—тырмалауга, катоклауга игътибар бирергә кирәк.

Үткән көзнең катлаулы килүе тунга сөрүне тиешле дәрәҗәдә оештырырга мөмкинлек бирмәде. Узган язга районда 14 мең гектарда җир эшкәртәсе калган иде. Аның никадәр авырлыклар тудыруын үз җилкәләрендә кичерсәләр дә, кайбер хуҗалыклар быел да аннан тиешле нәтиҗә ясамаганнар. Бүген 11 хуҗалык тунга сөрүгә керешмәгән әле. Сабанчыларның район конкурсында тунга сөрүгә куелган таләпләр җентекләп аңлатылды, бурычлар җиткерелде. Әмма әлеге эшнең башында ук һәр елдагы кимчелекләрнең кабатлануы сизелә: тунга сөрүне алтөрәнсез сөрәләр, борылыш полосалары юк, беренче һәм соңгы бураздалар сыйфатына игътибар бирелми, багана төпләрен алдан эшкәртмиләр. Хуҗалыкларга якын арада тунга сөрү звенолары оештырып, аларның группа ысулы белән җитештерүчән эшләвенә ирешергә кирәк. Тунга сөрүнең 50—70 проценты август аенда башкарылырга тиеш—бу безнең төп максат.

**Н. МУСИН,**
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең баш агрономы.

# Һәркайда да дәртле хезмәт

## Басу киңлегендә

Табигать тә елның-елында игенче алдына яңа сынаулар куя. Игеннәр өлгергән вакытта бер тамчы да төшмәгән яңгыр, соңгы вакытта ешаеп китте. Дөрес, игенчеләрнең моңа кәефе төшми, чөнки соңлабрак булса да аның бәрәңгегә, көнбагышка, чөгендергә, кукурузга, көтүлекләргә файдасы булуына, уңышны күтәрүенә өметен өзми ул. Яңгырлар эшне генә бераз тоткарлыйлар.

Әлбәттә, басудагы уңышны югалтусыз ала белергә дә кирәк. Монда инде төзек техника, оештыру һәм уңган игенчеләр барысын да хәл итә. Хуҗалыкта боларның барысы да бар дип ышанычы белән әйтергә була. Уракка төшү алдыннан комбайннар тикшерү үтте. Нигездә техника төзек, басуда ватылырлык түгел. Ә инде шулай да көтелмәгән хәлләр килеп чыкса, Вазыйх Гомәровның техник ярдәм күрсәтү машинасы һәрвакыт янда. Анда Рәхим Сафинның эретеп ябыштыру агрегаты да тагылган. Комбайннарның герметиклаштырылган булуы югалтуларга юл яба.

Ә уңган игенчеләр биредә җитәрлек.

—Игеннәрне тезмнәргә салуда Сабир Әхсәнов җитәкләгән звено егетләре бик тырышып эшләделәр,—ди колхозның партоешма секретаре Рифкать Бәдретдинович Фәхриев,—Таһир Гомәров, Вахит Хисмәтов, Сәлихҗан Ибраһимов һәм 11 классны тәмамлаганнан соң туган авылы кырларында ата-бабадан калган игенче һөнәрен дәвам иттерүче яшьләр Шамил Зиннуров, Ильяс Хәсәнов, Әнис Фәхриев. Алмаз Сәгыйров фидакарь хезмәт күрсәтәләр.

Әхәт Исхакович Ибраһимов һәм Рәис Азатович Абдрахмановлар басуга чыккан тәүге көннән үк югары җитештерүчәнлеккә ирештеләр. Бүгенге көндә дә алар «ДОН-1500» комбайнында 2500 центнердан артык арыш суктырып, район буенча да алдынгылар рәтендә баралар.

Хуҗалыкта 210 гектар мәйданда борчак 2 көндә җыелып беткән. 650 гектар мәйдандагы арышның да без барганда соңгы гектарлары суктырыла иде.

Комбайннарның җитештерүчәнлеген арттыру һәм явымлы һава шартларын исәпкә алып, хуҗалыкта тактика да анык билгеләнгән. Кырларга башта 12 комбайннан торган урдыру звеносы чыга, ә алар артыннан тезмнәрне җыеп суктыруга барлык комбайннар да төшә. Басуларның тигез, иркен булуы мондый эрелэтелгән звено белән эшләргә мөмкинлек бирә.

Аерым уру-сугу ысулы белән эшләү, ашлыкны турыдан җыюга караганда мәшәкатьле булса да, бердән, бөртекне чүптән арындырырга мөмкинлек бирсә, икенчедән, югалтуларны киметә, диләр хуҗалыкта. Бу һәркемнең ахыргы нәтиҗә белән кызыксынуыннан чыга. Чөнки уңыш мул булса, колхозчыларга ашлык һәркемнең хезмәтенә карап биреләчәк.

Халыкны икмәк, колхоз малларын фураж белән тәэмин иткәч, орлык салганнан соң, ашлык дәүләткә сатарга да кала. Хәзерге көнгә «Игенче» колхозы 690 центнер арышны элеваторга озатты.

Арыш басуында күзгә ташланган тагын бер күренеш турында әйтеп үтми булмый. Басуда комбайннар артыннан суктырылган салам бер дә калмый диярлек, чөнки аларның күбесе салам ваклагыч белән тәэмин ителгән. Һәм бу вакланган салам махсус арбаларга төялеп фермалар янына кайтарылып өелә. Бу бердән терлекчеләргә уңайлык тудырса, икенчедән, җирне сөрүне комбайннарның эзләренә басып алып барырга мөмкинлек бирә.

Ә инде ваклатылмый калган салам исә йорт башыннан билгеле бер күләмдә халыкка кайтартыла, калганы эскерткә өелә.

## Ындыр табагында

Аның эше белән безне өлкән үлчәүче Әмир ага Зиннуров таныштырып йөрде. Колхозда ындыр табагы яңа уңышны кабул итүгә яхшы хәзерләнгән. Без килгәндә анда кызу эш бара иде. Кырдан кайткан борчак урнаштырылып беткән. Басудан кайткан арыш Салих Хәсәнов, Дамир Мәхмүтов һәм пенсиядә булса да булышырга килгән Әхмәт Әхсәнов эшләтә торган ЗАВ-20 агрегатларында чистартылып, сортларга аерыла һәм орлыкка, фуражга аерым урнаштырыла.

Машинист Ринат Хәкимов эшләтә торган ашлык чистарткыч-төягеч машина механизмнары да һәрвакыт төзек, эшкә өзеклек китермиләр.

Ашлык эшкәртү агрегатлары һәм амбарлар арасында Рәис Гафуровның ГАЗ-53 автомашинасы һәрдаим йөреп тора. Хәлим Камаловның тракторы исә фуражга дигән ашлыкны амбарда урнаштыруда эшли иде. Аларга ярдәмгә ындыр табагына чөгендер сирәкләүдән бушаган апалар да килгәннәр. Минзифә Минебаева, Хәдичә Сабирова, Минниса Сәлахова көндез эшләсә, икенче сменага аларны Сәлимә Мәҗитова, Фәимә Ибраһимова алыштыра. Монда мәктәп балалары да теләп булышалар.

## Мастерскойда

Монда да эш киеренке. Урып-җыю чорында техниканы ышанычлы һәм тиз арада төзәтеп булырлык итеп оештырылган. Кадрлар ике сменада да комплектланган.

Бригадирның техника буенча ярдәмчесе Нәгыйм Зәйнуллин хуҗалыктагы барлык техниканың төзеклеген тәэмин итүдә үзенең зур җаваплылыгын яхшы аңлый. Шуңа ул көне-төне мастерскойда хәзер.

Мастерской мөдире Сәлим Сафиуллин монда эшләүче яшьләр һәм вакытның җитдилеген аңлап лаеклы ялларын бүлеп кире эш урыннарына чыккан ветераннар турында бик җылы итеп сөйли. Чынлап та токарьлар—Әхәт Әхсәнов, үз һөнәренә 30 еллап тугрылыклы булып калган Әхәт Хәсәновлар, бакырчы да, вулканизаторчы да, аккумуляторчы да Вәлиулла Галиуллин, эретеп ябыштыручылар— ветеран Рәхим ага Гайсин, Рафик Насыйбуллин, слесарь—сугыш һәм хезмәт ветераны Вәгыйзь Фәйзетдинов, тимерче Сәлих ага Миннехановларны ничек мактап телгә алмыйсың. Колхозда урып-җыюга бөтен төр техниканың җитешле булуында аларның да өлеше зур. Чөнки монда искергән дип техниканы ташлау юк. Булдырылган кадәресен үзләре җыеп, төзәтеп эштә кулланалар.

x x x

**Урак әле дәвам итә. «Игенче» колхозында аны зур хәзерлек белән башлап җибәргәннәр, арпа, солы, бодай һ.б. культураларны җыеп алуда да игенчеләрнең эш темпларын югары тотып, бурычларын намус белән башкарып чыгачакларына ышанабыз.**

**Р. ШӘЙХУЛЛИНА.**

## *Кышка тәмле азык*

Урып-җыю эшләре белән бергә Ульянов исемендәге колхоз кышкылыкка терлек азыгы хәзерләүне дә арткы планга куймый. Хатыйп Даутов белән Хәбибулла Гиниятуллин бер участоктан катнаш азыкны чабып бетерделәр. Кырдан яшел массаны Т-150 тракторы белән Ильяс Гайнуллин һәм УТТ шоферлары А. Алексеев, Р. Әхмәтов, В. Ерышев үз вакытында кайтарып торалар. Әлегә 1200 тонна сенаж салынды. Әлбәттә, моның белән генә эш тәмамланмый. Алга таба кышкыга башка төрле азык әзерләү дәвам итәчәк.

**А. ДАУТОВА,**
экономист.

